Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Советының унөченче утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

24 ноябрь, 2021 ел № 36

Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Иске Шигали торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы 2019 елның 08 ноябрендәге 54 номерлы (2021 елның 17 декабрендәге 35 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) Шигали авыл җирлеге Советы карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шигали авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. Иске Шигали авылында гражданнар җыеннарын торак пункт территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча билгеләргә:

1.1. Новоселов урамы гражданнары өчен 2021 елның 7 декабрендә 14.00 сәгатьтә Үзәк урамындагы 45 нче йорт адресы буенча КФҮ (МФЦ) бинасы янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2022 елда Шигали авыл җирлеге Иске Шигали авылы Новоселов урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Тынычлык урамы гражданнары өчен 2021 елның 7 декабрендә 15.00 сәгатьтә Тынычлык урамындагы 4 нче йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2022 елда Шигали авыл җирлеге Иске Шигали авылы Тынычлык урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Казан урамы гражданнары өчен 2021 елның 8 декабрендә 14.00 сәгатьтә Үзәк урамындагы 45 нче йорт адресы буенча КФҮ (МФЦ) бинасы янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2022 елда Шигали авыл җирлеге Иске Шигали авылы Казан урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Шигали авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башлыгы — В.М. Салимов